Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2019 елның 12 апреле № 102

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2017 елның 05 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 46 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы гамәлдәге законнарга туры китерү максатында КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2017 елның 05 сентябрендәге 46 номерлы карары белән расланган Олы Карамалы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк ур., 4 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 нчы йорт,
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе Э.И.Байдамшин